| СОВЕТ<br>НУРЛАТСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>НОРЛАТ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ**
**05 апрель 2022 ел**

Норлат ав.

**КАРАР**
**№ 65**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен шартлар тудыру вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябреннән 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 һәм 15 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының "Норлат авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге Советы:

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен шартлар тудыру вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшырырга:

1) Милли һәм җирле социаль-икътисадый, экологик, мәдәни һәм башка үзенчәлекләрне исәпкә алып, муниципаль программаларны (подпрограммаларны) Формалаштыру һәм гамәлгә ашыру;

2) муниципаль берәмлек территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүнең финанс, икътисадый, социаль һәм башка күрсәткечләрен анализлау һәм аны үстерү, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү фаразлары буенча чараларны куллануның нәтиҗәлелеген анализлау;

3) муниципаль берәмлек территориясендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын формалаштыру һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү;

4) кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мәнфәгатьләрен чагылдыручы коммерцияле булмаган оешмалар һәм әлеге оешмаларның структур бүлекчәләре эшчәнлегенә ярдәм итү;

5) кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә координация һәм киңәшмә органнарын төзү.

2. Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге башкарма комитеты белән килешү төзергә.

3. Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру ел саен Норлат авыл җирлеге бюджетыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбенә башкарыла.

4. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый информация рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы информация сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Норлат авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Норлат авылы, Гагарин урамы, 46 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Норлат авылы, М. Фәйзуллин урамы, 17 йорт («Идел Аръягы»үзәге бинасы) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Норлат авыл җирлеге Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Норлат авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе** **И.М.Саттаров**